**2020 елда Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү турында**

2020 елда җирле үзидарә органнарында гражданнар тарафыннан язмача җибәрелгән һәм шәхси кабул итүдә алынган **8824** мөрәҗәгать каралды (2019 елда – **9032** мөрәҗәгать).

Барлык кергән мөрәҗәгатьләрнең гомуми саныннан:

**6025**е – язмача мөрәҗәгатьләр (2019 елда – **5315**).

**4617** язмача мөрәҗәгать электрон рәвештә алынды (ведомствоара электрон документлар әйләнеше, Интернет-кабул итүе һәм электрон почта аша) (2019 елда – **3958**).

**1408** мөрәҗәгать шәһәрнең җирле үзидарә органнарына кулдан (кулга, почта, курьер аша) бирелде (2019 елда – **1357).**

Татар телендә **61** мөрәҗәгать керде (2019 елда – **42**).

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә барлыгы **7909** имза белән **226** коллектив мөрәҗәгать алынды (2019 елда – 12072 кешедән 261 коллектив мөрәҗәгать)**.** Коллектив мөрәҗәгатьләрне имзалаучылар саны – 4163 кешегә, ә коллектив мөрәҗәгатьләр саны 35кә кимегән.

Шәһәр Хакименә һәм Башкарма комитетның структур бүлекчәләренә шәһәр халкын борчыган мәсьәләләрне хәл иткән өчен рәхмәт белдерелгән **35** хат алынды.

Гражданнарның бер генә мөрәҗәгате дә җирле үзидарә органнарында игътибарсыз калмый.

**6025** мөрәҗәгатьнең **977**се уңай хәл ителде һәм бу гомуми санның 16,2 % ын тәшкил итте, **143**е ведомство буйсынуындагы оешмаларга адресланды, калган мөрәҗәгатьләр буенча аңлатмалар һәм рекомендацияләр бирелде.

Үзләренең социаль хәлен күрсәтүчеләрнең составы түбәндәге категория гражданнарга бүленә:

- пенсионерлар: **360** (5,98 %);
- эшләүчеләр: **218** (3,62 %);
- эшмәкәрләр: **118** (1,96 %);
- эшсезләр: **105** (1,74 %);
- хезмәткәрләр: **55** (0,92 %);
- хуҗабикәләр: **34** (0,56 %);
- укучылар: **28** (0,46 %);
- интеллигенция: **18** (0,30 %)
- социаль хәлен күрсәтмәүчеләр: **5089** (84,46 %).

Мөрәҗәгать итүчеләр арасында үзенең льготалы категориягә ия булуын күрсәтүчеләрнең күпчелеге: күп балалы гаиләләр – **229** (3,80 %), инвалидлар – **176** (2,92 %), хәрби хәрәкәт ветераннары – **24** (0,40 %), ялгыз ата-аналар – **18** (0,30 %), Бөек Ватан сугышы ветераннары – **9** (0,15 %).

Гражданнардан кергән язмача мөрәҗәгатьләрне анализлау шуны күрсәтә, 2020 елда шәһәр халкы өчен түбәндәге мәсьәләләр аеруча актуаль саналган:

- торак-коммуналь хуҗалыгы – ***1827*** *(2019 – 1956);*

- мәгариф һәм мәктәпкәчә тәрбия бирү – ***563*** *(2019 – 515);*

- юл хуҗалыгы – ***548*** *(2019 – 363);*

- төзелеш – ***455*** *(2019 – 510);*

- торак өлкәсе – ***428*** *(2019 – 311);*

- социаль тәэмин итү – ***392*** *(2019 – 149);*

- җирдән файдалану – ***365*** *(2019 – 373);*

- сәламәтлек саклау – ***211*** *(2019 – 123);*

- сәүдә һәм кулланучылар хезмәте – ***206*** *(2019 – 190);*

- транспорт хезмәте күрсәтү– ***205*** *(2019 – 158);*

- законлылык һәм хокук тәртибен тәэмин итү – ***195*** *(2019 – 150);*

- хезмәт һәм эш белән тәэмин итү – ***160*** *(2019 – 97);*

- финанс өлкәсе – ***106*** *(2019 – 151).*

**2799** чаллылы шәхси кабул итүдә булган (2019 ел белән чагыштырганда 918гә кимрәк (2019 – 3717).

**875** мөрәҗәгать буенча чаралар күрелде, мөрәҗәгать иткән **1924** граждан аңлатмалар алды.

Шәһәр Хакиме һәм Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан **402** чаллылы турыдан-туры кабул ителде.

Кергән мөрәҗәгатьләрнең мониторингы көн саен уздырыла, мөрәҗәгатьләрне үзвакытында карау контрольдә тотыла, үтәү дисциплинасы буенча анализ ясала.

Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән мәсьәләләр компетенция кысаларында оператив рәвештә хәл ителә.

Мөрәҗәгать итүче һәр кешегә гамәлдәге законнарга нигезләнеп язмача җаваплар һәм аңлатмалар бирелде.